| ГЛАВА<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШЛЫГЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.12.2022 п.г.т. Алексеевское № 61

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 05.07.2018 № 72 «Алексеевск муниципаль районында керемнәрне легальләштерү һәм тормыш дәрәҗәсен күтәрү буенча район ведомствоара комиссиясе турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында» 05.07.2018 ел, № 72 карары белән расланган Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турындагы Нигезләмәнең 5 пункты нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә,

**карар бирәм:**

1.Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында» 05.07.2018 ел, №72 карарына 1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башлыгының 05.07.2018 № 72
карарына 1 нче кушымта

**Тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм керемнәрне легальләштерү район ведомствоара комиссиясе СОСТАВЫ**

| | |
| --- | --- |
| Гайнуллин О.А. | - Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе; |

| | |
|---|---|
| Язынин Р.С. | - Башкарма комитет җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары, комиссия рәисе урынбасары; |
| Куприянова Т.В. | -Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад бүлеге башлыгы, комиссия секретаре; |

**Комиссия әгъзалары:**

| | |
|---|---|
| Гайсин М.Р. | - Башкарма комитет җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Хәмзина Е.А. | - Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары (килештерү буенча); |
| Мусин Г.К. | - Алексеевск районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Леденцов О.Н. | - Алексеевск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы рәисе; |
| Тимонина Н.Ю. | - «Алексеевск районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры; |
| Әхмәтова Г.Х. | - Алексеевск муниципаль районында РФ Пенсия фондының ТР буенча идарәсе башлыгы (килештерү буенча); |
| Шәйхаттаров Ф.Р. | - Алексеевск районы прокуроры (килештерү буенча); |
| Әхмәтҗанов Р.Р. | - Татарстан Республикасының Алексеевск районындагы Россия ЭЭМ бүлеге башлыгы (килештерү буенча); |
| Куделько С.П. | - Федераль суд приставлары хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Алексеевск район суд приставлары бүлеге өлкән суд приставы (килештерү буенча); |
| Матвеева Л.Н. | - Чистай шәһәрендә (Алексеевск ш. т. б.) Дәүләт статистикасы бүлегенең әйдәп баручы белгеч-эксперты (килештерү буенча); |
| Белякова Н.Ю. | - Татарстан Республикасы буенча № 12 ГУ РО ФСС РФ филиалы баш белгече (килештерү буенча); |
| Газизов А.Т. | - Татарстан Республикасы МРИ ФНС №12 Федераль салым хезмәте (килештерү буенча) башлыгы; |
| Сабирҗанов Д.К. | - Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенең Чистай районара тикшерү бүлеге җитәкчесе (килештерү буенча).» |

2. Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 05.07.2018 № 72 «Алексеевск муниципаль районында тормыш дәрәҗәсен күтәрү һәм

керемнәрне легальләштерү буенча район ведомствоара комиссиясе турында» карарының 2 нче кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Комиссия утырышлары кирәк булганда үткәрелә, ләкин кварталга кимендә бер тапкыр. Комиссия утырышында әгъзаларның гомуми саныннан кимендә яртысы катнашса, комиссия утырышы хокуклы санала.

Комиссиянең һәр әгъзасы бер тавышка ия. Комиссия карарлары комиссия әгъзаларының гомуми саныннан гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч санала. Утырыш беркетмәсенә комиссия утырышы уздырылганнан соң 3 (өч) көн эчендә комиссия рәисе имза сала»;

- 8 пунктны яңа абзац белән тулыландырырга:

«8. Комиссия рәисе урынбасары:

- Комиссия рәисе вазыйфаларын ул булмаганда башкара;
- Комиссия рәисе йөкләмәләрен үти».

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Алексеевск муниципаль районы Башлыгы** **С.А. Демидов**